КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 30 март г.Казань № 311

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы мәсьәләләре» 2012 ел, 24 октябрь, 902 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 4 май, 303 нче; 2015 ел, 29 сентябрь, 725 нче; 2015 ел, 13 октябрь, 763 нче; 2016 ел, 26 август, 595 нче; 2018 ел, 22 август, 684 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1280 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1204 нче; 2020 ел, 15 июнь, 491 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 975 нче; 2022 ел, 20 октябрь, 1117 нче; 2023 ел, 7 февраль, 115 нче; 2023 ел, 2 май, 550 нче; 2023 ел, 14 август, 978 нче; 2024 ел, 13 август, 652 нче; 2025 ел, 25 гыйнвар, 35 нче; 2025 ел, 3 июнь, 406 нчы; 2026 ел, 16 гыйнвар, 13 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы турындагы нигезләмәгә, 4.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештереп, ведомство бүләкләрен гамәлгә кую, алар белән Агентлык хезмәткәрләрен һәм медиатармакны үстерүдә һәм камилләштерүдә актив катнашучы башка затларны Агентлык тарафыннан чыгарылган хокукый акт нигезендә бүләкләү турында карарлар кабул итәргә һәм аларга карата башка төр бүләкләүне кулланырга.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин